ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«08» июня 2021 ел № 93-р

**Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре төркемнәренең 2021 елның июнь-август айларында җәйге чорда эшчәнлеген вакытлыча туктатып тору турында**

Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе һәм муниципаль мәгариф учреждениеләре үтенечнамәләре нигезендә, мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән, 2021 елның июнь-август айларында җәйге чорда мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре төркемнәре биналарын яңа 2021 - 2022 уку елына әзерләү буенча чаралар (агымдагы ремонт эшләре) үткәрү максатында:

1. Эшчәнлеге 2021 елның июнь-август айларында мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре биналарында агымдагы ремонт эшләрен уздыруга бәйле рәвештә туктатыла торган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының беркетелгән мәктәпкәчә мәгариф оешмалары исемлеген һәм төркемнәр санын расларга.

2. Әлеге күрсәтмәнең 1 пункты белән расланган исемлек нигезендә мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре төркемнәрен агымдагы ремонт эшләрен үткәрүгә бәйле рәвештә 2021 елның июнь-август чорына ябарга һәм аларның эшен туктатып торырга.

3. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгына:

- мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре төркемнәренең эшчәнлеген агымдагы ремонт эшләрен уздыруга бәйле рәвештә 2021 елның июнь-август айларына туктатып тору турында мәгълүматны ата-аналарга (законлы вәкилләргә) җиткерергә;

- 2021 елның июнь-август айларында мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре биналарын яңа 2021 - 2022 уку елына әзерләү чараларын (агымдагы ремонт эшләре) оештырырга һәм җәйге чорда үткәрүне тәэмин итәргә;

- мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренә агымдагы ремонт эшләрен башкарган вакытта балалар бакчалары биналарында куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре турында инструктаж үткәрергә;

- мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре төркемнәренең эшчәнлеген агымдагы ремонт эшләрен уздыруга бәйле рәвештә 2021 елның июнь-август айларында җәйге чорга туктатып тору турында мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренең мәгълүмат стендында мәгълүмат урнаштырырга.

4. Әлеге күрсәтмә нигезендә мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренә:

- оештыру-штат чараларын үткәрергә;

- балигъ булмаганнарның хокукларын яклауга һәм гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрергә;

- мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвен яңадан исәпләү чараларын күрергә;

- әлеге күрсәтмәне гамәлгә ашыру буенча локаль норматив актлар кабул итәргә;

- мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренә агымдагы ремонт эшләрен башкарган вакытта балалар бакчалары биналарында куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре турында инструктаж үткәрергә.

5. Әлеге күрсәтмәнең гамәли көче 2021 елның 01 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге күрсәтмәне Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э.Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районы
Башкарма комитетының
08.06.2021 № 93-р
күрсәтмәне белән расланган

**Эшчәнлеге 2021 елның июнь-август айларында мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре биналарында агымдагы ремонт эшләрен уздыруга бәйле рәвештә туктатыла торган Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының беркетелгән мәктәпкәчә мәгариф оешмалары исемлеген һәм төркемнәр саны**

| № | Оешма атамасы | Туктатып тору вакыты | Эшчәнлекләре туктатыла торган төркемнәр саны |
|---|---|---|---|
| 1. | "Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Ләбиб Айтуганов исемендәге Девәтернә төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 01.07.2021 - 11.08.2021 | 1 |
| 2. | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Бертуган Бубилар исемендәге Иж-Бубый урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 01.07.2021 - 31.08.2021 | 2 |
| 3. | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Исәнбай урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 01.07.2021 - 11.08.2021. | 2 |
| | | 12.08.2021 - 31.08.2021 | 1 |
| 4. | "Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районынын Кадрәк башлангыч мәктәп-балалар бакчасы" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 01.07.2021 - 31.08.2021 | 1 |
| 5. | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Кадыбаш урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (Кадыбаш авылы, Иске Эсләк авылы) | 01.07.2021 - 11.08.2021.. | 2 |
| 6. | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Кичкетаң урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 01.07.2021 - 11.08.2021. | 1 |
| 7. | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Куләгәш башлангыч мәктәбе балалар бакчасы | 01.06.2021 - 31.07.2021 | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (Күләгәш ав., Ташлы) | | |
| 8. | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (Көчек авылы, Варклед-Бодья авылы) | 01.07.2021 - 11.08.2021. | 2 |
| 9. | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районынын Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (Яңавыл, Биектау) | 01.07.2021 - 31.08.2021 | 2 |
| 10. | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районынын Салагыш урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (Салагыш ав., Ямурза авылы) | 10.06.2021 - 10.08.2021 | 2 |
| 11. | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Сарсак-Омга лицее муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 01.07.2021 - 11.08.2021. | 2 |
| | | 12.08.2021 - 31.08.2021. | 1 |
| 12. | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Азево төп гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 01.07.2021 - 31.08.2021 | 1 |
| 13. | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районынын "Шаршада башлангыч мәктәбе - балалар бакчасы" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 12.07.2021 - 23.08.2021 | 1 |
| 14. | Әгерже муниципаль районы Бима авылында муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе-балалар бакчасы | 01.06.2021 - 31.08.2021 | 1 |
| 15. | Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Красный Бор авылының «Теремок» балалар бакчасы | 01.06.2021 - 31.08.2021 | 1 |
| 16. | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Тирсә авылынын «Миләүшә» балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | 01.06.2021 - 31.08.2021 | 2 |
| 17. | «Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Бима урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү | 01.06.2021 - 31.07.2021 | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | учреждениесе (Пеләмеш авылы) | | |
| 18. | Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районынын «Кырынды башлангыч мәктәп-балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 01.07.2021 - 31.08.2021 | 1 |